| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.06.2026 г.Казань № 30-13/тп-2026

Тоташтырыла торган җылылык йөкләнеше егәрлеге берәмлегенә исәпләгәндә «Интеграция» катнаш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьне җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтыруга (технологик тоташтыруга) түләүне билгеләү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Рәсәй Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы, 2021 елның 30 ноябрендәге карарлары нигезендә 2115 номерлы «Җылылык белән тәэмин итү системаларына тоташтыру (технологик тоташтыру) кагыйдәләрен, җылылык белән тәэмин итү системаларына тоташтыру (технологик тоташтыру) хезмәтләреннән дискриминациясез файдалану кагыйдәләрен, җылылык энергиясен, җылылык йөртүчене тапшыру хезмәтләреннән дискриминациясез файдалану кагыйдәләрен раслау турында, шулай ук Рәсәй Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Рәсәй Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләрне үзгәртү һәм үз көчен югалткан дип тану хакында», Тарифлар буенча Федераль хезмәт боерыгы белән «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) исәпләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы нигезләмә белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.06.2010 ел, № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында Нигезләмә белән, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты Идарәсе утырышының 10.06.2026 ел, № 18-ПР Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Интеграция» катнаш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятен (алга таба – «Интеграция» катнаш челтәр компаниясе» ҖЧҖ) җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик тоташтыру) өчен түләүне әлеге карарга кушымта нигезендә тоташтырыла торган җылылык йөкләнеше егәрлеге берәмлегенә исәпләп билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән түләү карар үз көченә кергән

көннән 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. «Интеграция» катнаш челтәр компаниясе» ҖЧҖ Рәсәй Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 110 номерлы карары белән расланган мәгълүмат ачу стандартларына туры китереп, киләсе җайга салу чоры өчен түләү билгеләү турында карар кабул ителгән көннән 30 көннән дә соңга калмыйча, җәмәгатьчелеккә ачык мәгълүматны ачарга тиеш.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В.Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитеты
карарына кушымта
10.06.2026 № 30-13/тп-2026

Тоташтырыла торган җылылык йөкләнеше егәрлеге берәмлегенә исәпләгәндә «Интеграция» катнаш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьне җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтыруга (технологик тоташтыруга) түләү

мең сум/Гкал/сәгать (НДСны исәпкә алмыйча)

| № т/с | Исем | Күрсәткеч |
|---|---|---|
| 1 | Мөрәҗәгать итүчеләр объектларын тоташтыру чараларын үткәрү чыгымнары (П$_1$) | 6,740 |
| 2 | Гамәлдәге җылылык челтәрләреннән яисә җылылык энергиясе чыганакларыннан мөрәҗәгать итүчеләр объектларын тоташтыру нокталарына кадәр җылылык челтәрләрен төзү (реконструкцияләү) чыгымнары (П2.1), шул исәптән: | |
| 2.1 | Җир өсте салу | |
| 2.1.1 | 250 мм га кадәр | 5973,54 |
| 2.1.2 | 251 - 400 мм | - |
| 2.1.3 | 401 - 550 мм | - |
| 2.1.4 | 551 - 700 мм | - |
| 2.1.5 | 701 мм һәм югарырак | - |
| 2.2 | Җир асты салу, шул исәптән: | |
| 2.2.1 | канал салу | |
| 2.2.1.1 | 250 мм га кадәр | - |
| 2.2.1.2 | 251 - 400 мм | - |
| 2.2.1.3 | 401 - 550 мм | - |
| 2.2.1.4 | 551 - 700 мм | - |
| 2.2.1.5 | 701 мм һәм югарырак | - |
| 2.2.2 | каналсыз салу | |
| 2.2.2.1 | 250 мм га кадәр | |
| 2.2.2.2 | 251 - 400 мм | - |
| 2.2.2.3 | 401 - 550 мм | - |
| 2.2.2.4 | 551 - 700 мм | - |
| 2.2.2.5 | 701 мм һәм югарырак | - |
| 3 | Гамәлдәге җылылык челтәрләреннән яисә җылылык энергиясе чыганакларыннан алып мөрәҗәгать итүчеләр объектларын тоташтыру нокталарына кадәр җылылык пунктларын төзү (реконструкцияләү) чыгымнары (П2.2) | - |
| 4 | Керем салымы | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге